| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**ГЛАВА**<br>**Табарлинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**Әгерже муниципаль районы**<br>**Тәбәрле авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.11.2019 Тәбәрле авылы № 4

Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Тәбәрле авыл җирлеге Яңа Аккуҗа авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрле авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрле авыл җирлеге башлыгы к а р а р б и р д е:

1.Яңа Аккуҗа авыл клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2019 елның 21 ноябренә 10 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга: «Тәбәрле авыл җирлеге Яңа Аккуҗа авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I группа инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә сафларында хезмәт итүче затлардан, иректән мәхрүм итү урыннарында булган затлардан тыш, 2020 елда 350 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

1. Яңа Аккуҗа авылы урамнарын кардан чистарту.
2.Сокман авылының Нариман урамына юл салу өчен таш сатып алу, юлга таш җәю һәм тигезләү.
3.Сокман авылынын су башнясыннан трассага кадәр суүткәргеч торбаларын алыштыру.
4.Сокман авылы өчен пожар гидранты сатып алу һәм аны урнаштыру .

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Тәбәрле авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында.бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Табарлинского сельского поселения
Тәбәрле авыл җирлеге Советы

М.М.ХАРАСОВ